**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**29 август 2019 ел** **№ 120**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советының 2013 елның 19 декабрендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында”гы 69 номерлы Карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советының 2013 елның 19 декабрендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында”гы 69 номерлы Карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

28 маддәнең 5 пунктында “Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль Башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “әлеге кодекс нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.8 һәм 3.9 өлешләрендә каралган тәртиптә” сүзләренә алмаштырырга;”;

29 маддәнең 3 пунктының 9 пунктчасында “проект документлары” сүзләреннән соң “(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.8 һәм 3.9

өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен да кертеп)”сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4 йорт;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк урамы, 3 йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а йорты, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башлыгы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы рәисе В.П. Оленин**